ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11 ноябрь 2016ел № 5925

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезнамәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 нче карары, шәһәр Уставы нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезнамәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен килешү төзү хокукына аукцион оештыру турында нигезнамәне, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2016 елның 11 ноябрендәге
5925 нче карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 нче карары белән расланган Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе, шәһәр Уставы нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Тәртип муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир участокларында, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир участокларында стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга төп таләпләрне билгели.

3. Әлеге Тәртип максатында стационар булмаган сәүдә объекты дигәндә инженерлык-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташкан яки тоташмаган (технологик кушылу) булуга бәйсез рәвештә җир белән бәйле булмаган вакытлы корылма, төзелмә, конструкция яки җайланмадан гыйбарәт сәүдә объекты (мобиль сәүдә объектларыннан тыш), шул исәптән капиталь төзелеш объекты булмаган җәмәгать туклануы объекты һәм хезмәт күрсәтү объекты аңлашыла.

4. Әлеге Тәртип нигезләмәләре түбәндәге сәүдә объектларының урнашу һәм эшләп тору өлешенә кагылмый:

1) биналарда, төзелмәләрдә һәм корылмаларда урнашкан стационар булмаган сәүдә объектларына;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнарының яки законнар нигезендә вәкаләтләнгән, яисә билгеләнгән тәртиптә алар белән килешенгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының (алга таба – җирле үзидарә органнары) карары буенча үткәрелә торган массакүләм бәйрәм, иҗтимагый-сәяси, мәдәни-массакүләм һәм спорт-массакүләм чараларына хезмәт күрсәтү белән бәйле

мөнәсәбәтләргә, шулай ук ярминкәләрдә товарлар сату белән бәйле мөнәсәбәтләргә.

5. Стационар булмаган сәүдә объектларының төрләре:

павильон – сәүдә залы булган һәм бер яки берничә сатучы өчен эш урынына исәпләнгән ябык пространстволы аерым урнашкан төзелмәдән (төзелмә өлешеннән) яки корылмадан гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты (100 кв. метрга кадәр). Павильонда товар запасы саклау өчен бүлмә булырга мөмкин;

киоск – эчендә бер сатучы өчен эш урыны белән җиһазландырылган һәм товар запасын саклауны гамәлгә ашыра торган ябык пространстволы сәүдә залы булмаган корылмадан гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

сәүдә галереясы – җылылык изоляциясе функциясен башкармый торган яктылык үткәрүче бердәм вакытлыча түбә астына берләштерелгән һәм сатып алучыларның тоткарлыксыз йөрү урыны белән тәэмин ителгән, бер-берсенә каршы симметрияле урнашкан биштән артык булмаган (бер рәттә) махсуслаштырылган павильон яки киосклар җыелмасыннан торган, бердәм архитектура стилендә эшләнгән стационар булмаган сәүдә объекты;

сәүдә автоматы (вендинг автоматы) – җайланма урнашкан урында куллану төргәгендәге данәле товарларны сатучы катнашыннан башка сату, түләү һәм бирү процессын автоматлаштыру өчен билгеләнгән техник җайланмадан гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

лоток – сәүдә залы һәм товарлар саклау өчен бүлмәсе булмаган, мәйданында бер көн сәүдә итү өчен товар запасы урнаштырыла торган һәм бер эш урынына исәпләнгән, прилавка белән җиһазландырылган җиңел сүтеп-җыела торган корылмадан гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

палатка – бер яки берничә сатучыга эш урыны һәм бер көн сәүдә итү өчен товар запасы урнаштыру өчен билгеләнгән һәм прилавка белән җиһазландырылган, прилавка ягыннан ябык булмаган эчке пространство барлыкка китерүче җиңел сүтеп-җыела торган корылмадан гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

бакча культуралары мәйданчыгы – сезонлы бакча культуралары сату өчен билгеләнгән аерым ачык мәйданчык төрендәге яки сәүдә палаткасы урнаштырылган махсус җиһазландырылган вакытлы корылмадан гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

чыршы базары – Яңа елга (Раштуа бәйрәменә) табигый ылыслы агачлар һәм ылыслы агач ботаклары сату өчен аерым ачык мәйданчык төрендәге махсус җиһазландырылган вакытлы корылмадан гыйбарәт стационар булмаган сәүдә объекты;

сезонлы кафелар, туңдырма һәм салкын эчемлекләр өчен урам суыткычлары (тәгәрмәчтә булмаган) – эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары тарафыннан файдаланыла торган, төрле урыннарда күп тапкыр файдалану мөмкин булган җиңел, шул исәптән сүтеп-җыела торган корылмадан гыйбарәт сәүдә объекты.

## 2 бүлек. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга һәм тышкы күренешенә таләпләр

6. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру Башкарма комитет карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасында (алга таба – схема) билгеләнгән урыннарда гамәлгә ашырыла.

7. Стационар булмаган сәүдә объектларын урам һәм юлларның кызыл линия чикләрендә урнаштырган очракта, аларны урнаштыру тротуар чикләрендә ныгытылган (асфальт түшәлгән) мәйданчыкта һәм тротуар буенча стационар булмаган сәүдә объектының кырый элементыннан йөри торган юл читенә кадәр 1,5 метрдан ким булмаган ирекле йөрү юлы калган шартларда гына мөмкин.

8. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштырганда җәяүлеләр йөрү өчен комачауламый торган уңайлы автотранспорт юлы күздә тотылырга тиеш. Товар һәм җиһазларны бушату автомобильне тротуарга кертмәгән килеш гамәлгә ашырылырга тиеш.

9. Урнаштырыла торган стационар булмаган сәүдә объектлары (хезмәт күрсәтү объектлары) янгын һәм медицина транспортының, Россия Федерациясе гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы транспорт чараларының гамәлдәге бина, төзелмә һәм корылма янына керүенә комачауларга тиеш түгел.

10. Стационар булмаган сәүдә объектлары янәшәсендәге территория кичке вакытта яктыртылырга тиеш.

11. Стационар булмаган сәүдә объектларында оешманың исеме, эш режимы, урнашу урыны, юридик адресы күрсәтелгән элмә такта булырга тиеш.

12. Стационар булмаган сәүдә объектлары (хезмәт күрсәтү объекты) янәшәсендәге территорияне җыештыру гамәлдәге төзекләндерү кагыйдәләренә һәм халыкның санитария-эпидемиология иминлеге өлкәсендәге таләпләргә туры китереп башкарылырга тиеш.

Товарны, төрү материалларын, чүпне төзекләндерү элементларына, стационар булмаган сәүдә объектлары (хезмәт күрсәтү объекты) түбәсенә һәм алар янәшәсендәге территориягә өю рөхсәт ителми.

13. Стационар булмаган сәүдә объектлары янына сәүдә-суыту җиһазлары кую рөхсәт ителми.

14. Стационар булмаган сәүдә объектының тышкы күренешенә таләпләр Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

## 3 бүлек. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү төзү тәртибе

15. Гариза бирүчегә, урнаштыру схемасы белән билгеләнгән урыннарда стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукы бирү стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына ачык аукцион

(алга таба – Аукцион) формасында үткәрелүче сату нәтиҗәләре буенча төзелә торган килешү нигезендә, яисә әлеге Тәртиптә билгеләнгән очракларда сату үткәрмичә гамәлгә ашырыла.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү (алга таба – Урнаштыруга килешү) әлеге Тәртиптә билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм хуҗалык итүче субъект (законнарда башкача каралмаган булса, шәхси эшмәкәр яки юридик зат) арасында төзелә.

16. Урнаштыруга килешү төзү белән бәйле чараларны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе үткәрә.

17. Урнаштыруга килешү Схемага кертелгән билгеле урында стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга хокукны раслаучы документ булып тора.

18. Аукционны оештыру һәм үткәрү Башкарма комитет тарафыннан гамәлгә ашырыла.

19. Аукционнар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен килешү төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибе нигезендә үткәрелә.

20. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешү биш елга төзелә.

21. Аукцион нәтиҗәләре буенча төзелә торган Урнаштыруга килешү буенча еллык түләү күләме аукцион йомгаклары буенча билгеләнә яисә аукцион үтмәде дип танылган очракта, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешүнең башлангыч (минималь) бәясе күләмендә билгеләнә.

22. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга аукцион үткәрмичә төзелә торган килешү буенча еллык түләү күләме, Россия Федерациясенең бәяләү эшчәнлеге турындагы законнары нигезендә, урнаштыруга килешү төзү хокукының базар кыйммәтен бәяләү турындагы хисапка туры китереп билгеләнә.

23. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга еллык түләү күләме Урнаштыруга килешү төзелгәннән соң кимендә бер елдан соң, ләкин елына бер тапкырдан еш түгел һәм Россия Федерациясенең федераль бюджет турындагы законында билгеләнгән инфляция дәрәҗәсе зурлыгыннан армаган күләмдә билгеләнә.

## 4 бүлек. Аукцион үткәрмичә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешү төзү тәртибе

24. Аукцион үткәрмичә Урнаштыруга килешү түбәндәге очракларда төзелә:

1) стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга элек төзелгән килешү буенча үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәгән Хуҗалык итүче субъект тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасында

күздә тотылган шул ук урында элек урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектын яңа срокка урнаштырганда;

Әлеге Тәртипнең 33 пунктында күрсәтелгән хәлләрнең күзәтелүе стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга элек төзелгән килешү буенча үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәү булып тора;

2) 2015 елның 1 мартына кадәр гамәлдә булган һәм стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруны күздә тоткан җир участогын арендалау буенча төзелгән килешү нигезендә үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәгән Хуҗалык итүче субъект тарафыннан шул ук урында элек урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштырганда;

Рәттән ике айдан артык аренда түләве кертмәү стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыруга җир участогын арендалау буенча элек төзелгән килешү нигезендә үз йөкләмәләрен тиешенчә үтәмәү булып тора;

3) җир участокларын арендалау буенча 2015 елның 1 мартына кадәр гамәлдәге һәм әлеге тәртипне кабул иткәннән соң расланган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру схемасына кермәгән стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруны күздә тоткан килешүләре булган Хуҗалык итү субъектларына компенсация (буш) урыннары биргәндә, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан түбәндәге карарлар кабул ителү сәбәпле стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга килешүнең гамәлдә булу вакыты срогыннан алда туктатылганда:

- стационар булмаган сәүдә объектының урнашуы күрсәтелгән эшләрне гамәлгә ашыруга комачаулаган очракта, автомобиль юлларын ремонтлау һәм (яки) реконструкцияләү кирәклеге турында;

- автомобиль юлларын төзекләндерү элементларының саклагыч юл корылмаларын урнаштыру буенча эшләр башкару турында;

- линия объектларын яки муниципаль әһәмияткә ия капиталь төзелеш объектларын урнаштыру турында;

- федераль законнарда каралган башка нигезләр буенча.

4) аяк киемнәре төзәтү буенча хезмәт күрсәтү өчен стационар булмаган сәүдә объектын урнаштырганда. Ике яки берничә заявка булган очракта, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешү сату нәтиҗәләре буенча төзелә;

5) басма продукция сата торган стационар булмаган сәүдә объектын урнаштырганда. Ике яки берничә заявка булган очракта, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешү сату нәтиҗәләре буенча төзелә;

6) күрсәтелгән станционар булмаган сәүдә объекты, шул исәптән җәмәгать туклануы объекты урнаштырылган бина, төзелмә, корылма урнашкан җир участогы белән чиктәш җир участогында стационар булмаган сәүдә объектын урнаштырганда, стационар булмаган сәүдә объектының хуҗасы (арендаторы) тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектын, шул исәптән җәмәгать туклануы объектын урнаштырганда.

25. Сату үткәрмичә Урнаштыруга килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

1) әлеге Тәртипнең 24 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәү;

2) Хуҗалык итүче субъект тарафыннан дөрес булмаган мәгълүматлар бирү;

3) әлеге Тәртипнең 24 пунктындагы таләпләргә туры килә торган элек бирелгән заявка булу.

26. Әлеге Тәртипнең 24 пунктында каралган очракларда, Хуҗалык итүче субъект Урнаштыруга килешү төзү турындагы гариза белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать итә. Гариза Хуҗалык итүче субъект тарафыннан шәхсән бирелергә яки почта аша җибәрелергә мөмкин.

Күрсәтелгән гариза нигезендә Башкарма комитет, шундый гариза кергән көннән соң 10 эш көне эчендә, Хуҗалык итүче субъект заявкасының әлеге Тәртипнең 24 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерүне гамәлгә ашыра һәм Урнаштыруга килешү төзү турында яки Урнаштыруга килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә, Башкарма комитет гаризада күрсәтелгән реквизитлар буенча гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Урнаштыруга килешү төзү турында карар кабул ителгән очракта Башкарма комитет имзаланган Урнаштыруга килешүне гариза бирүчегә бирә.

Урнаштыруга килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта Башкарма комитет, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Урнаштыруга килешү төзүдән баш тарту турында хат бирә.

## 5 бүлек. Компенсация (буш) урыннарын бирү тәртибе

27. Урнаштыруга килешү яки әлеге Тәртип үз көченә кергәнче төзелгән җир участогын арендалау килешүе туктатылган очракта, дәүләти яки муниципаль ихтыяҗлар өчен стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру урыны күздә тотылган җир участогын тартып алу турында карар кабул ителгәнлектән тиешле килешү төзелгән хуҗалык итүче субъектка карата стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру урынын Схемадан чыгару сәбәпле, хуҗалык итүче субъектка компенсация (буш) урыны бирелә.

28. Гамәлдәге Схемада булмаган компенсация урыннарын бирүгә хуҗалык итүче субъектларның хокукларын тормышка ашыру максатында Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе Башкарма комитетның районнар Хакимияте Башлыклары һәм Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе белән берлектә компенсация урыннары исемлеген билгели.

Компенсация урыннары реестрын Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе алып бара.

Компенсация урыннарының якынча исемлегенә кертелгән урыннар бары тик компенсация урыннары буларак бирелергә мөмкин.

29. Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру урынын Схемадан чыгару турында карар кабул ителгәнче 30 календарь көннән соңга калмый, язма рәвештә Урнаштыруга килешү яки җир участогын арендалау килешүе төзегән затка, сәбәпләрен күрсәтеп, шул объектны схемадан чыгару турында хәбәр итә.

Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру урынын Схемадан чыгару турындагы хәбәрдә, хуҗалык итүче субъетка Схемадан чыгарыла торган урын өчен алмашка гамәлдәге Схемадагы буш урыннар арасыннан компенсация урыны сайлау яки стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен расланган компенсация урыннары исемлегеннән башка компенсация урыны сайлау турында тәкъдим булырга тиеш.

Хуҗалык итүче субъект сәүдә объектын урнаштыру урынын Схемадан чыгару турындагы хәбәрне алган көннән соң 10 эш көне эчендә Башкарма комитетка гамәлдәге Схемадагы буш урыннар арасыннан урын яки расланган компенсация урыннары исемлегеннән башка урын сайлау турында хәбәр җибәрә.

30. Хуҗалык итүче субъект Схемадагы буш урыннар арасыннан яки компенсация урыннары исемлегеннән компенсация урыны сайлаган очракта, Башкарма комитет компенсация урыны сайлау турындагы хәбәрне алганнан соң 3 эш көне эчендә Хуҗалык итүче субъектка, Урнаштыруга килешү төзү өчен Башкарма комитетка килергә кирәклеге турында хәбәр җибәрә. Хуҗалык итүче субъект яки аның вәкиле әлеге хәбәрне алганнан соң 10 эш көне эчендә, Урнаштыруга килешү төзү өчен вәкаләтле органга килергә тиеш.

Хуҗалык итүче субъект Башкарма комитет тәкъдим иткән компенсация урыннарыннан баш тарткан очракта, Хуҗалык итүче субъект стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру өчен компенсация урыны бирүгә хокукын югалта.

## 6 бүлек. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешүне өзү тәртибе

31. Урнаштыруга килешүне өзү якларның килешенүе, суд карары яки гражданнар законнары нигезендә, Урнаштыруга килешүдәге якның Килешүне үтәүдән берьяклы баш тартуы сәбәпле рөхсәт ителә.

32. Урнаштыруга килешүне өзү өчен нигезләр булган очракта, Урнаштыруга килешүне өзү өчен нигезләр ачыкланган көннән соң өч көн эчендә Башкарма комитет Хуҗалык итүче субъектка Урнаштыруга килешүне өзү турында белдерү кәгазе җибәрә. Хуҗалык итүче субъект, күрсәтелгән белдерү кәгазен алган көннән соң 30 көн эчендә, үз карамагындагы стационар булмаган объектны җир участогыннан алырга бурычлы.

33. Хуҗалык итүче субъект тарафыннан объектны белдерү кәгазендә күрсәтелгән срокта һәм ирекле рәвештә демонтажлау үтәлмәгән очракта,

Башкарма комитет карары белән билгеләнгән тәртип нигезендә, Башкарма комитет мәҗбүри демонтажлауны гамәлгә ашыра.

34. Башкарма комитет инициативасы буенча Урнаштыруга килешү түбәндәге очракларда берьяклы тәртиптә өзелергә мөмкин:

1) әлеге тәртипнең 24 пунктының 3 пунктчасына каралган очракларда;

2) хуҗалык итүче субъект тарафыннан рәттән ике айдан артык, урнаштырган өчен түләү кертелмәгән очракта. Шулай ук урнаштыруга килешүне өзү турындагы хәбәр, аны өзү күздә тотылган датага кадәр 30 календарь көн кала хуҗалык итүче субъектка җибәрелергә тиеш;

3) Хуҗалык итүче субъект тарафыннан 30 календарь көн эчендә, стационар булмаган сәүдә объектын максатчан файдалану турындагы килешү шартларын бозуны яисә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешүдә билгеләнгән стационар булмаган сәүдә объектының мәйданын арттыруга бәйле кимчелекне бетерү турындагы күрсәтмә үтәлмәгәндә. Күрсәтелгән күрсәтмә буенча шикаять бирелгәндә, хуҗалык итүче субъектка әлеге күрсәтмәне законсыз дип тану турында таләпләрне канәгатьләндерүдә кире кагу турында законлы көченә кергән суд карары стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешүне өзү өчен нигез булып тора.

## 7 бүлек. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру буенча эшчәнлекне мәгълүмати тәэмин итү

35. Башкарма комитет «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында түбәндәге мәгълүматларны урнаштырырга бурычлы:

1) Схемага кертелгән стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен урыннар турында;

2) компенсация урыннарының якынча исемлеге.

36. Мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

1) стационар булмаган сәүдә объекты урынының номеры;

2) стационар булмаган сәүдә объектының адрес ориентиры;

3) стационар булмаган сәүдә объектының төре;

4) стационар булмаган сәүдә объекты эшчәнлегенең төре (махсуслашуы);

5) стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру урынының мәйданы (кв.м.).

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2016 елның 11 ноябрендәге
5925 нче карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен
килешү төзү хокукына аукцион үткәрү
тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру өчен килешү төзү хокукына аукцион үткәрү тәртибе (алга таба – Тәртип) «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставы нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Тәртип нигезендә үткәрелә торган аукционнар катнашучылар составы буенча һәм тәкъдимнәр бирү формасы буенча ачык булып тора.

3. Аукцион предметы (лот) – биш ел срокка Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасында билгеләнгән урында стационар булмаган бер сәүдә объектын урнаштыруга килешү төзү хокукы.

4. Оештыру-хокукый формасына, милекчелек формасына, урнашу урынына бәйсез рәвештә, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү (алга таба – Урнаштыруга килешү) төзүгә дәгъва итүче теләсә кайсы юридик зат яки шәхси эшмәкәр аукционда катнашучы булып тора ала.

5. Аукционны оештыручы булып Башкарма комитетның муниципаль заказ бүлеге йөзендә «Башкарма комитет» МКУ тора.

6. Аукцион үткәрү өчен Башкарма комитет карары белән аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерүне һәм акционда катнашучыларны сайлап алуны, аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерү беркетмәсен, аукцион беркетмәсен, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру хокукына килешү төзүдән баш тарту беркетмәсен алып баруны гамәлгә ашыра торган аукцион комиссиясе төзелә.

7. Аукцион үткәрү турындагы мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла, «Челнинские известия» газетасында бастырыла.

## 2. Аукционны оештыру һәм үткәрү тәртибе

8. Аукционны оештыручы аукцион турындагы документларны эшли һәм раслый.

9. Аукцион үткәрү турындагы хәбәр аукционда катнашуга заявка бирү тәмамланганчы кимендә утыз көн алдан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла, «Челнинские известия» газетасында бастырыла.

Аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) аукционны оештыручының исеме, урнашу урыны, почта адресы, электрон почта адресы һәм элемтә телефоны номеры;

2) стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру урынының Схемадагы номеры, Схема нигезендә урнашу урыны, стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыру урынының мәйданы, стационар булмаган сәүдә объектының төре һәм стационар булмаган сәүдә объекты эшчәнлегенең төре;

3) Урнаштыруга килешү буенча еллык түләү күләме (лот бәясе);

4) Урнаштыруга килешүнең гамәлдәге срогы;

5) аукцион турындагы документларны тапшыру срогы, урыны һәм тәртибе, «Интернет» челтәрендә аукцион турындагы документлар урнаштырылган сайтларның электрон адреслары;

6) задаток кертү турында таләп, шулай ук задаток күләме, задаток кертү өчен счет реквизитлары;

7) сатып алуда катнашучыларга аукцион турындагы документларның нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү тәртибе, аларны бирү срогының башлану һәм тәмамлану даталары;

8) аукционны оештыручы аукцион турындагы хәбәргә һәм документларга үзгәрешләр кертергә хокуклы булган срок;

9) аукционны оештыручы аукцион үткәрүдән баш тартырга хокуклы булган срок.

10. Аукцион турындагы документларда, аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә булган мәгълүмат һәм белешмәләрдән тыш, түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) аукционда катнашуга заявка, шул исәптән электрон документ формасында бирелә торган заявка эчтәлегенә, составына һәм формасына таләпләр һәм аны тутыру буенча күрсәтмә;

2) Урнаштыруга килешү буенча түләү формасы, сроклары һәм тәртибе;

3) Урнаштыруга килешү бәясен (лот бәясен) арттыру ягына яңадан карау тәртибе, шулай ук яклар тарафыннан Урнаштыруга килешү бәясен киметү ягына яңадан карау мөмкин булмау буенча күрсәтмә;

4) аукционда катнашуга заявкалар бирү тәртибе, урыны, срогы башлану һәм тәмамлану датасы һәм вакыты;

5) аукционда катнашучыларга таләпләр;

6) аукционда катнашуга заявкаларны кире алу тәртибе һәм срогы;

7) аукцион турындагы документларның нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү формасы, тәртибе, башлану һәм тәмамлану датасы;

8) аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерү урыны, датасы һәм вакыты;

9) аукцион үткәрү урыны, датасы һәм вакыты;

10) задаток кертү турында таләп, задаток күләме, задаток кертү срогы һәм тәртибе, задаток күчерү өчен счет реквизитлары;

11) аукционда катнашуга бердәнбер заявка бирелү сәбәпле аукцион үтмәде дип танылган яисә бердәнбер гариза бирүче аукционда катнашучы дип танылган очракта, аукцион беркетмәсе яисә аукционда катнашуга гаризаларны карап тикшерү беркетмәсе «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылган көннән соң кимендә ун көн эчендә, Урнаштыруга килешү проекты имзаланырга тиешле срок;

12) Урнаштыруга килешү төзегәндә һәм аны үтәгәндә аукцион турындагы документларда күрсәтелгән килешү шартларын яклар килешенүе буенча һәм берьяклы тәртиптә үзгәртү рөхсәт ителмәү турында күрсәтмә;

13) аукцион шартлары, аукционда катнашучы белән Урнаштыруга килешү төзү тәртибе һәм шартлары ачык оферта булып тору, ә аукционда катнашуга заявкалар әлеге офертаның акцепты булып тору турында күрсәтмә.

11. Аукцион турындагы документларга, аукцион турындагы документларның аерылгысыз өлеше булып торган Урнаштыру килешүенең проекты теркәлергә тиеш (берничә лот буенча аукцион үткәргән очракта – һәр лотка карата Килешү проекты).

12. Аукцион турындагы документлардагы мәгълүматлар аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән мәгълүматларга туры килергә тиеш.

13. Теләсә кайсы кызыксынучы зат, аукцион документларының аңлатмаларын сорап, сатуларны оештыручыга мөрәҗәгать итә ала.

Күрсәтелгән запрос конкурста катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамлану датасына кадәр өч эш көненнән соңга калмый кергән очракта, күрсәтелгән запрос кергән датадан соң ике эш көне эчендә, аукционны оештыручы язма рәвештә яки электрон документ формасында аукцион документларының аңлатмаларын җибәрергә бурычлы.

14. Аукционны оештыручы үз инициативасы буенча яки кызыксынучы затның запросы нигезендә, аукционда катнашуга заявкалар бирү тәмамлану датасына кадәр биш көннән соңга калмый, аукцион турындагы документларга үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Аукцион предметын һәм задаток күләмен үзгәртү рөхсәт ителми.

15. Аукционда катнашу өчен кызыксынучы зат (алга таба – гариза бирүче) аукционда катнашуга заявка бирә.

Аукционда катнашуга заявка аукцион документларында билгеләнгән срокта һәм форма буенча бирелә. Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 438 маддәсе нигезендә, аукционда катнашуга заявка бирү оферта акцепты булып тора.

16. Аукционда катнашуга заявка гариза бирүче турында мәгълүматларны һәм документларны, шулай ук задаток кертүне раслый торган документларны яки документлар (задаток күчерүне раслый торган түләү йөкләмәсе) күчермәсен үз эченә алырга тиеш.

Гариза бирүче турында мәгълүматларга һәм документларга түбәндәгеләр керә:

а) фирма исеме (исеме), оештыру-хокукый формасы, урнашу урыны турында мәгълүматлар, почта адресы (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны турында мәгълүматлар (физик зат өчен), элемтә телефоны номеры;

б) аукцион үткәрү турындагы хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә яки шул өземтәнең нотариаль расланган күчермәсе (юридик затлар өчен), аукцион үткәрү турындагы хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә яки шул өземтәнең нотариаль расланган күчермәсе (шәхси эшмәкәрләр өчен), аукцион үткәрү турындагы хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә алынган, тиешле дәүләт законнары нигезендә юридик зат яки физик зат буларак дәүләт теркәве турында документларның тиешенчә расланган рус теленә тәрҗемәсе (чит ил затлары өчен);

в) затның гариза бирүче – юридик зат исеменнән эшләр башкаруга вәкаләтләрен раслаучы документ (физик затка ышаныч язуыннан башка гариза бирүче исеменнән эш итәргә хокук бирә торган, физик затны вазыйфага билгеләү турында яки сайлау турында карар яисә билгеләү турында боерык күчермәсе (алга таба – җитәкче)). Гариза бирүче исеменнән башка зат эш иткән очракта, аукционда катнашуга заявкада, гариза бирүче исеменнән эш итү өчен, гариза бирүченең мөһере белән расланган һәм гариза бирүченең җитәчесе (юридик затлар өчен) яки җитәкченең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган ышаныч язуы яисә шул ышаныч язуының нотариаль расланган күчермәсе булырга тиеш. Күрсәтелгән ышаныч язуы гариза бирүченең җитәкчесенең вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган очракта, аукционда катнашуга заявкада шул затның вәкаләтләрен раслаучы документ та булырга тиеш;

г) гариза бирүченең оештыру документларының күчермәләре (юридик затлар өчен);

д) гариза бирүченең – юридик затның ликвидацияләнүе хакында карар булмау турында, гариза бирүчене – юридик затны, шәхси эшмәкәрне банкрот дип тану һәм конкурс производствосы ачу хакында арбитраж суды карары булмау турында, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә гариза бирүченең эшчәнлеге туктатылу хакында карар булмау турында декларация.

17. Гариза бирүче аукционның һәр предметы (лот) буенча бер генә заявка бирергә хокуклы.

18. Аукционда катнашуга заявкалар аукцион турындагы документларда күрсәтелгән форма буенча һәм тәртиптә, шулай ук аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән урында һәм срок чыкканчы бирелә.

19. Аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән срокта кергән аукционда катнашуга һәр заявка аукционны оештыручы тарафыннан рәсмиләштерелә. Гариза бирүченең таләбе буенча аукционны оештыручы, кабул итү датасын һәм вакытын күрсәтеп, заявканы кабул итеп алу турында расписка бирә.

20. Аукционда катнашуга заявкалар кабул итүнең билгеләнгән срогы тәмамланганнан соң кабул ителгән заявкалар карап тикшерелми һәм заявка кабул ителгән көннән соң икенче эш көнненнән дә соңга калмый гариза бирүчеләргә кире кайтарыла. Задаток, аукцион беркетмәсе имзаланган датадан соң биш эш көне эчендә, гариза бирүчеләргә кире кайтарыла.

21. Аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамланганда бер генә заявка кергән яки бер заявка да кермәгән очракта, аукцион үтмәде дип таныла. Аукцион турындагы документларда ике яки күбрәк лот күздә тотылган очракта, аукцион бер генә заявка кергән яки бер заявка да кермәгән лотларга карата гына үтмәде дип таныла.

22. Аукцион комиссиясе аукционда катнашуга заявкаларның аукцион турындагы документларда билгеләнгән таләпләргә туры килү һәм гариза бирүчеләрнең Россия Федерациясе законнарында шундый катнашучыларга карата билгеләнгән таләпләргә туры килү предметына карап тикшерә.

Аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерү срогы заявкалар бирү срогы тәмамлану датасыннан соң ун көннән артырга тиеш түгел.

23. Аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре нигезендә, аукцион комиссиясе тарафыннан гариза бирүчене аукционда катнашуга кертү турында һәм гариза бирүчене аукционда катнашучы дип тану турында яки шул гариза бирүчене аукционда катнашуга кертүне кире кагу турында карар кабул ителә һәм ул аукционда катнашуга заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Аукционда катнашу өчен, бер гариза бирүче тарафыннан бер үк лотка мөнәсәбәтле ике яки күбрәк заявка бирелү факты билгеләнгән очракта, әлеге гариза бирүче тарафыннан алдан бирелгән заявкалар кире алынмаган булса, әлеге гариза бирүченең шул лотка мөнәсәбәтле аукционда катнашуга заявкалары карап тикшерелми һәм барысы да әлеге гариза бирүчегә кире кайтарыла.

Беркетмә аукцион комиссиясе тарафыннан алып барыла һәм заявкаларны карап тикшерү тәмамланган көнне аукцион комиссиясенең утырышта катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәдә гариза бирүчеләр турында мәгълүматлар, гариза бирүчене аукционда катнашуга кертү һәм аны аукционда катнашучы дип тану турында яки дәлилләр китереп һәм гариза бирүче туры килмәгән нигезләмәләрне, аның аукционда катнашуга заявкасы туры килмәгән аукцион турындагы документларның нигезләмәләрен күрсәтеп, аукционда катнашуга кертүне кире кагу турында карар булырга тиеш. Заявкаларны карап тикшерү

беркетмәсе имзаланган датадан соң бер эш көне эчендә әлеге беркетмә аукционны оештыручы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла. Аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы тәмамланганда бер генә заявка бирелгән яки бер заявка да бирелмәгән очракта, күрсәтелгән беркетмәгә аукцион үтмәде дип тану турындагы мәгълүмат кертелә.

24. Аукционны оештыручы, заявкаларны карап тикшерү беркетмәсе имзаланган датадан соң биш эш көне эчендә, задатокны аукционда катнашуга кертелмәгән гариза бирүчегә кире кайтарырга бурычлы.

Барлык гариза бирүчеләрне дә аукционда катнашуга кертүне кире кагу турында яки бер генә гариза бирүчене аукционда катнашучы дип тану турында карар кабул ителгән очракта, аукцион үтмәде дип танныла.

25. Аукционны оештыручы аукционда катнашучыларга аукционда турыдан-туры яки үз вәкилләре аша катнашу мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы.

Аукцион, аукцион комиссиясе әгъзалары һәм аукционда катнашучылар (аларның вәкилләре) катнашында, аукционны оештыручы тарафыннан үткәрелә.

Аукцион, аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән Урнаштыруга килешүнең еллык түләү күләмен (лот бәясен) «лот адымы»на күтәрү юлы белән үткәрелә.

«Аукцион адымы» аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән Урнаштыруга килешүнең еллык түләү күләменең (лот бәясенең) биш проценты күләмендә билгеләнә. Аукционда бер генә катнашучы катнашкан яки аукционны үткәргәндә аукционда катнашучыларның берсе дә катнашмаган очракта, яисә аукцион предметының башлангыч бәясе турындагы тәкъдим өч тапкыр игълан ителгәннән соң, аукцион предметы турында аукцион предметының тагын да югарырак бәясен күздә тоткан бер тәкъдим дә кермәгән очракта, аукцион үтмәде дип танныла.

Аукцион түбәндәге тәртиптә үткәрелә:

1) Аукцион, аукцион турындагы хәбәрдә һәм документларда күрсәтелгән вакытта, урында, тәртиптә ачык рәвештә үткәрелә;

2) аукцион комиссиясе турыдан-туры аукционны үткәрә башлау алдыннан аукционга килгән аукционда катнашучыларны (аларның вәкилләрен) терки. Аукционны берничә лот буенча үткәргән очракта, аукцион комиссиясе һәр лот башланыр алдыннан, шул лотка мөнәсәбәтле заявка биреп, аукционга килгән аукционда катнашучыларны (аларның вәкилләрен) терки. Теркәү вакытында аукционда катнашучыларга (аларның вәкилләренә) номер сугылган карточкалар (алга таба – карточкалар) бирелә;

3) аукцион, аукционда сатучы тарафыннан аукцион (лот) үткәрелә башлауны, лот номерын (аукцион берничә лот буенча үткәрелгән очракта), Урнаштыруга килешү предметын, килешүнең (лотның) еллык түләү күләмен, «аукцион адымы»н игълан итүдән башлана;

4) аукционда сатучы тарафыннан килешүнең еллык түләү күләме һәм килешүнең еллык түләвенең һәр чираттагы күләме игълан ителгәннән соң,

килешүнең әлеге еллык түләү күләме нигезендә килешү төзергә әзер булган очракта, аукционда катнашучылар карточка күтәрәләр;

5) килешүнең еллык түләвенең һәр чираттагы күләмен аукционда сатучы килешүнең еллык түләү күләмен «аукцион адымы»на арттыру юлы белән билгели. Килешүнең еллык түләвенең һәр чираттагы күләмен игълан иткәннән соң, аукционда сатучы билетны беренче булып күтәргән аукционда катнашучының билет номерын атый һәм әлеге аукционда катнашучыны күрсәтә. Аннан соң аукционда сатучы «аукцион адымы» нигезендә еллык түләүнең аннан соңгы күләмен игълан итә;

6) аукционда сатучы тарафыннан игълан ителгән еллык түләү күләме нигезендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешү төзергә әзер аукционда катнашучылар булмаган очракта, аукционда сатучы әлеге еллык түләү күләмен 3 тапкыр кабатлый.

Еллык түләү күләмен 3 тапкыр игълан иткәннән соң, аукционда катнашучыларның берсе дә билет күтәрмәсә, аукцион тәмамлана. Аукционда сатучы тарафыннан аталган бәя буенча билетны беренче булып күтәргән аукционда катнашучы аукционда җиңүче дип таныла;

7) аукцион тәмамлануга, аукционда сатучы стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешү төзү хокукын тормышка ашыру турында игълан итә, еллык түләү күләмен һәм аукционда җиңүченең билет номерын атый.

26. Стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга килешүнең иң югары еллык түләү күләмен тәкъдим иткән катнашучы аукционда җиңүче дип таныла.

27. Аукцион үткәргәндә аукционны оештыручы мәҗбүри рәвештә аукционны аудио яки видеога яздыруны гамәлгә ашыра һәм аукцион беркетмәсен алып бара. Әлеге беркетмә аукционны үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында, аукционда катнашучылар турында, Урнаштыруга килешүнең башлангыч (минималь) бәясе (лот бәясе) турында, килешү бәясе турында соңгы һәм соңыннан алдагы тәкъдим, аукционда җиңүченең һәм килешү бәясе турында соңыннан алдагы тәкъдимне ясаган катнашучының исеме һәм урнашу урыны (юридик зат өчен), фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны (физик зат өчен) турында мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш. Беркетмә аукцион үткәрелгән көнне аукцион комиссиясенең катнашкан барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмә ике нөсхәдә төзелә, берсе аукционны оештыручыда кала.

Аукцион беркетмәсе, ул имзаланган көннән соң икенче көнне, аукцонны оештыручы тарафыннан шәһәрнең рәсми сайтына урнаштырыла.

28. Урнаштыруга килешүне төзү гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

29. Аукционда катнашуга бердәнбер заявка бирелү сәбәпле яисә бер генә гариза бирүче аукционда җиңүче дип танылу сәбәпле аукцион үтмәде дип танылган очракта, әгәр күрсәтелгән заявка аукцион турындагы документларда каралган таләпләргә һәм шартларга туры килсә, аукционны оештыручы аукционда бердәнбер заявка бирүче зат белән, шулай ук

аукционның берДәнбер катнашучысы дип танылган зат белән аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән шартларда һәм бәя буенча Урнаштыруга килешү төзергә бурычлы.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова